МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

17.05.2023 № 258-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен раслау хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $78^1$ статьясының 1 пунктындагы икенче абзацы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бюджет һәм автоном учреждениеләргә башка максатларга субсидия бирү күләмен һәм шартларын билгели торган норматив хокукый актларга һәм муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» 2020 елның 22 февралендәге 203 номерлы карары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатларга Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү күләмен һәм шартларын билгеләүгә вәкаләтле булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары турында һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларын көчен югалткан дип тану турында» 2022 елның 28 февралендәге 178 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибен (кушымтада бирелә) расларга.

2. Юридик бүлек җитәкчесе Т.А.Барсуковага әлеге боерыкның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.

3. Боерык рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Боерык үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Р.К.Гомәровка йөкләргә.

Министр Р.Ә.Кузюров

Татарстан Республикасы
Урман хуҗалыгы
министрлыгының 2023 елның
17 маендагы 258-осн номерлы
боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган дәүләт бюджет учреждениеләренә башка максатларга финанс яктан тәэмин итү чыганагы Татарстан Республикасы бюджеты акчалары булган субсидияләр күләмен һәм аларны бирү шартларын билгеләү тәртибе

### I бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы аларга карата гамәлгә куючы функцияләрен һәм вәкаләтләрен гамәлгә ашыра торган түбәндәге дәүләт бюджет учреждениеләренә Татарстан Республикасы бюджетыннан башка максатларга субсидияләр (алга таба – субсидия, Учреждение) бирү күләмен һәм шартларын билгеләү механизмын билгели:

- «Лубян урман-техник көллияте» дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесенә;
- «Урман янгыннарын сүндерү үзәге» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениесенә;
- Татарстан Республикасы дәүләт бюджет учреждениеләренә («Урман хуҗалыгы» ДБУ).

2. Субсидияләр Учреждениегә түбәндәге максатларда бирелә:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 30 июлендәге 531 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 22 февралендәге 110 номерлы карары белән расланган «2014 - 2025 елларга Татарстан Республикасы мәгарифен һәм фәнен үстерү» дәүләт программасын; Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 23 декабрендәге 1023 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы гражданнарына социаль ярдәм» дәүләт программасын гамәлгә ашыру кысаларында чаралар үткәрү;

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне гамәлгә ашыру;

аларга тотылачак чыгымнар дәүләт хезмәте күрсәтүгә (эшне башкаруга) норматив чыгымнар исәбенә кертелмәгән очракта, Татарстан Республикасы милегендә булган мөлкәтне тоту чараларын гамәлгә ашыру;

мөлкәт сатып алу;

конференцияләр, семинарлар, күргәзмәләр, сөйләшүләр, очрашулар, киңәшмәләр, слетлар, съездлар, конгресслар, турнирлар, чемпионатлар оештыру;

төбәкара һәм халыкара хезмәттәшлек кысаларында чараларны гамәлгә ашыру;

Татарстан Республикасы территориясендә авария (гадәттән тыш хәл) килеп чыккан очракта, шул исәптән аварияләр, куркыныч табигый күренеш, һәлакәт, стихияле яки башка афәт нәтиҗәсендә торгызу эшләрен үткәрү;

мобилизацияле әзерлек һәм гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәү.

3. Учреждениегә субсидияләр, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын алучы буларак, тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына (алга таба – Министрлык) җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә бирелә.

## II бүлек. Субсидияне бирү шартлары һәм тәртибе

4. Субсидия алу өчен Учреждение Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:

аңлатма язуын, анда бюджет акчаларын бирү зарурлыгын нигезләү, шул исәптән субсидия суммасын исәпләү-нигезләү, шулай ук тиешле эшләрне башкаруга (хезмәтләрне күрсәтүгә), чаралар уздыруга, мөлкәт сатып алуга (күчемсез мөлкәттән тыш) башлангыч смета, шулай ук тәэминатчыларның (подрядчыларның, башкаручыларның) тәкъдимнәре, статистика белешмәләре һәм (яки) башка мәгълүмат була;

субсидия бирүнең максаты әлеге Тәртипнең 2 пунктының икенче, алтынчы, җиденче, сигезенче, тугызынчы абзацлары нигезендә чаралар үткәрү булса, чаралар программасы;

субсидия бирү максаты мөлкәтне сатып алу булса, сатып алуга планлаштырылган мөлкәт турында мәгълүмат;

түләүләрне алучылар булып торган физик затларның саны (уртача еллык саны) һәм мондый түләүләрнең төрләре турында мәгълүмат, әгәр субсидия бирү максаты булып Учреждение хезмәткәрләренә түләүләр башкару торса;

субсидия алу өчен документлар тапшыру көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага салым органы белешмәсе, ул Учреждениедә салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар буенча үтәлмәгән бурычның булмавын расларга тиеш;

субсидия алу өчен документлар тапшыру көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган дата буенча белешмә, ул Учреждениенең, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә, Татарстан Республикасы бюджетына субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен кайтару буенча вакытыннан алда бурычы булмавын расларга, җитәкче һәм баш бухгалтер, башка вәкаләтле зат тарафыннан имзаланырга тиеш.

5. Министрлык әлеге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгән документларны алганнан соң биш эш көне эчендә андагы мәгълүматларның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерә һәм субсидия бирү яки субсидияне бирүдән баш тарту

турында карар кабул итә.

6. Учреждение субсидияне алу өчен документлар тапшыру көненә кадәр 30 календарь көннән дә иртәрәк булмаган датага түбәндәге таләпләргә туры килергә тиеш:

Учреждениенең салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пеняларны, штрафларны түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе булмаска тиеш;

Учреждениенең, шул исәптән башка хокукый актлар нигезендә бирелгән, субсидияләрне, бюджет инвестицияләрен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарып бирү түләү вакыты узган бурычлары юк.

7. Учреждениегә субсидия бирүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез булып тора:

Учреждение тарафыннан тапшырылган документларның әлеге Тәртипнең 4 пунктында билгеләнгән таләпләргә туры килмәве яки әлеге документларның тапшырылмавы (тулы күләмдә тапшырылмавы);

Учреждение тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүматның дөрес булмавы;

бюджет законнары нигезендә Министрлыкка җиткерелгән, тиешле финанс елына (тиешле финанс елына һәм план чорына) субсидияләр бирү өчен бюджет йөкләмәләре лимитларының тиешле күләмдә булмавы.

8. Субсидия бирүдән баш тарткан очракта, Учреждение әлеге Тәртипнең 4 пунктында каралган документларны Министрлыкка кабат тапшырырга хокуклы.

9. Субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты боерыклары белән билгеләнә.

10. Субсидия бирү максатларына карап, аны бирү нәтиҗәләре:

әлеге Тәртипнең 2 пунктындагы икенче, дүртенче, алтынчы, җиденче, сигезенче, тугызынчы абзацлары нигезендә чаралар уздыруга субсидия бирелгән очракта, үткәрелгән чаралар саны (кимендә бер чара);

Учреждение хезмәткәрләренә түләүләрне башкаруга бирелгән субсидия исәбенә кабул ителгән йөкләмәләр күләме (100 процент күләмендә);

мөлкәт сатып алуга субсидия бирелгән очракта, сатып алынган мөлкәт объектлары саны (кимендә бер мөлкәт объекты).

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү вакыты – субсидия бирү елының 31 декабреннән дә соңга калмыйча.

11. Субсидия бирү турында карар кабул ителгәннән соң биш эш көне эчендә Министрлык һәм Учреждение Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән типлаштырылган форма буенча субсидия бирү турында килешү (алга таба – килешү) төзиләр, анда, шул исәптән, түбәндәгеләр була:

әгәр субсидия әлеге Тәртипнең 2 пунктының икенче абзацына ярашлы рәвештә бирелә икән, дәүләт программасы һәм ярдәмче программасының исемен күрсәтеп, субсидия бирү максатлары;

субсидияне бирү нәтиҗәләренең күрсәткечләре;

субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планы;

субсидиянең күләме;
субсидияне күчерү вакыты (графигы);
хисаплылык тапшыру чорлары;
Учреждение килешүдә билгеләнгән субсидия бирү максатларын, шартларын һәм тәртибен үтәмәгән очракта, субсидия суммаларын кире кайтару тәртибе һәм чорлары;
килешүгә үзгәрешләр кертү нигезләре һәм тәртибе, шул исәптән Министрлыкка субсидия бирү өчен элек җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары кимегән очракта да;
Министрлык карары буенча берьяклы тәртиптә килешүне вакытыннан алда туктату нигезләре, шул исәптән Учреждениене үзгәртеп кору яки бетерүгә (кушылдыру формасында үзгәртеп корудан тыш) һәм Учреждение тарафыннан әлеге Тәртип һәм (яки) килешү нигезендә билгеләнгән субсидия бирү максатларын һәм шартларын бозуга бәйле рәвештә дә;
Учреждение тарафыннан килешүне берьяклы тәртиптә өзүнең тыелган булуына бәйле рәвештә.
Кирәк булуга карап, Министрлык һәм Учреждение килешүгә өстәмә килешү яки Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән бер төр үрнәкләр нигезендә килешүне өзү турында өстәмә килешү төзи.
12. Министрлык килешүдә каралган чорда субсидияне Учреждениенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетына күчерә.

## III бүлек. Хисаплылыкка карата таләпләр

13. Учреждение Министрлыкка түбәндәгеләрне тапшыра:
хисап аеннан соңгы айның 10нчы көненнән соңга калмыйча, квартал саен, финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидияләр булган чыгымнарны гамәлгә ашыру турындагы хисаплылык;
ел саен, агымдагы финанс елының 20 гыйнварыннан да соңга калмыйча, субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү турында хисап һәм финанс хисап елы өчен субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү буенча чаралар планын тормышка ашыру турында хисап.
Хисапларның формалары килешүдә билгеләнә.
Министрлык килешүдә өстәмә хисаплылык бирү формаларын һәм чорларын билгеләргә хокуклы.

## IV бүлек. Субсидия бирүнең максатларын, шартларын һәм тәртибен һәм аларны үтәмәү өчен җаваплылыкны үтәү буенча контрольлекне гамәлгә ашыру тәртибе

14. Министрлык һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы Учреждениегә субсидия бирү максатлары һәм шартларының үтәлешен контрольдә тота.
15. Учреждение субсидия алу өчен яки субсидиядән файдалану турында

дөрес булмаган белешмәләр һәм документлар тапшырган, субсидия бирү шартларын һәм тәртибен бозган, шулай ук әлеге Тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән субсидияне тоту максатларын бозган, хисаплылык тапшырмаган өчен җаваплы була.

16. Гамәлгә куючы һәм дәүләт финанс контроленең вәкаләтле органы тарафыннан үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәсендә Учреждениенең субсидия бирү вакытында билгеләнгән максатларны һәм шартларны үтәмәве ачыкланган очракта, субсидия Министрлыкның тиешле таләбе Учреждение тарафыннан алынганнан соң 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешмәгән очракта, субсидия Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгыннан тиешле таләп алынган көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнә торган 30 көн эчендә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

17. Әлеге Тәртипнең 16 пунктында күрсәтелгән субсидияне кире кайтару чорын бозган очракта, Министрлык әлеге чор узганнан соң, эш көннәрендә санала торган җиде көн эчендә әлеге акчаларны Россия Федерациясе законнары нигезендә мәҗбүри тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына түләттерү буенча чаралар күрә.

18. Агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидия акчалары әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен Татарстан Республикасы бюджетына кире кайтарылырга тиеш.

Министрлык учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып агымдагы финанс елының 1 гыйнварына тотылмаган субсидиянең калган өлеше булып торган, үтәлмәгән йөкләмәләр булуы турындагы, субсидия бирү елыннан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба – учреждениенең субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгате), шулай ук учреждениенең әлеге йөкләмәләре (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турында карар кабул итә.

Министрлык агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турындагы карарны Учреждениенең субсидиянең калган өлеше буенча мөрәҗәгате алынган көннән башлап биш эш көне эчендә кабул итә.

19. Министрлыкның агымдагы финанс елында кулланылмаган субсидиянең калган өлешен әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә максатларга ирешү өчен юнәлдерү зарурлыгы булуы турындагы карары нигезендә субсидиянең калган өлеше әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә максатларга юнәлдерелгән чыгымнарны финанс яктан тәэмин итү өчен агымдагы елда файдаланылырга мөмкин.

20. Агымдагы финанс елында финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, учреждение тарафыннан әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен элегрәк түләнгән түләүләрне кире

кайтарудан акча күчкән очракта, Министрлык учреждениенең финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кайтарудан алынган акчалар торган үтәмәгән йөкләмәләр (физик затларга түләүләр буенча йөкләмәләрдән тыш) булуы турында субсидия бирелгән елдан соңгы елның 20 эш көне эчендә җибәрелгән мөрәҗәгате (алга таба – учреждениенең элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгате), шулай ук учреждениенең әлеге йөкләмәләре булуын һәм аларның күләмен раслый торган документлар (документларның күчермәләре) нигезендә әлеге Тәртипнең 2 пункты нигезендә билгеләнгән максатларга ирешү өчен учреждение тарафыннан аларны файдалану турында карар кабул итә.

Министрлык әлеге Тәртипнең 2 пунктында билгеләнгән максатларга ирешү өчен финанс яктан тәэмин итү чыганагы булып субсидия торган, Учреждение тарафыннан элегрәк башкарылган түләүләрне кире кайтарудан күчкән акчаларны агымдагы финанс елында файдалану турындагы карарны Учреждение элегрәк башкарылган түләүләрдән алынган акчалар буенча мөрәҗәгать иткән датадан башлап биш эш көне эчендә кабул итә.